**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

**«30» октября 2025ел** **№ 149**

Муниципаль торак фонды, шулай ук Теләче муниципаль районында шәхси торак фонды составына керүче инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия турында

«Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы» Ассоциациясенең 2025 елның 30 сентябрендәге 876 номерлы хатын карап, Россия Федерациясе Торак кодексының 12 һәм 15 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта торак урыннарны һәм гомуми мөлкәтне инвалидлар ихтыяҗларын исәпкә алып җайлаштыру чаралары турында» 2016 елның 9 июлендәге 649 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 20 декабрендәге 958 номерлы «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фонды, муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керүче торак урыннарга карата инвалидларның торак урыннарын инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып җайлаштыру чараларын координацияләү буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органын билгеләү турында» карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Муниципаль торак фонды, шулай ук Теләче муниципаль районында шәхси торак фонды составына керүче инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзергә.

2. Муниципаль торак фонды, шулай ук Теләче муниципаль районында шәхси торак фонды составына керүче инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия составын (алга таба текст буенча - комиссия) кушымта нигезендә расларга.

3. Комиссиянең эш тәртибен Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керүче инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү һәм эшләү тәртибен раслау турында»2017 елның 06 февралендәге 21/о номерлы боерыгы нигезендә гамәлгә ашырырга.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Кушымта

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«30» 10 2025 № 148
карары белән расланган

Муниципаль торак фонды, шулай ук Теләче муниципаль районында шәхси торак фонды составына керүче инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия составы

| | | |
|---|---|---|
| Низамов Б.М. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары, муниципаль комиссия рәисе; |
| Гыйниятуллин Д.С. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, муниципаль комиссия рәисе урынбасары; |
| Садыкова Г.Р. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече, муниципаль комиссия секретаре. |

Муниципаль комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Гайбадуллин И.И. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы; |
| Галимова Ф.М. | - | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Теләче муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Заһидуллин Р.Ш. | - | Теләче муниципаль районы Ветераннар (пенсионерлар) советы иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча); |
| Закиров Р.З. | - | ҖЧҖ «Теләче» идарәче компаниясе» директоры. |